ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27 август, 2026 ел № 9/5

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы депутаты статусы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2011 елның 26 маендагы 12/7 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы депутаты статусы турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2016 елның 7 апрелендәге 7/20, 2018 елның 21 февралендәге 23/12, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/22, 2019 елның 6 декабрендәге 34/15, 2020 елның 17 июнендәге 40/4, 2020 елның 11 августындагы 41/14, 2021 елның 3 ноябрендәге 9/6, 2023 елның 5 маендагы 23/5 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Депутатның вәкаләтләре сайланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш Шәһәр Советының тулы хокуклы составта беренче утырышын уздырган көннән туктатыла.»;

2) 5 статьяның 2 өлешен көчен югалткан дип санарга;

3) 20 статьяның бишенче абзацын көчен югалткан дип санарга.

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев